СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.02.2026 г. Агрыз № 8-2

«2026 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның Фараз планын (программасын) раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 13.11.2025 елның 3-3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 13.11.2025 елның 3-3 номерлы карары белән расланган 2026 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру Фараз планының (программасының) II бүлегенә, түбәндәге эчтәлекле 10 нчы юлны өстәп, үзгәреш кертергә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 10 | 238,6 кв.м мәйданлы торак булмаган 1965 елгы бина, 1974 елгы 46,1 кв.м мәйданлы веранда, кадастр номеры 16:01:080204:25 булган җир кишәрлегендә урнашкан, мәйданы 2261 кв.м. | ТР, Әгерҗе МР, Түбән Көчек авылы, Ленин ур., 15 й. | Бина - 16:01:080204:173, веранда - 16:01:080204:174 | ачык аукцион | 2 квартал | Билгеләнеше буенча файдаланылмый |

2. Әлеге карарны «Татмедиа» АҖ филиалының Әгерҗе районы «Әгерҗе хәбәрләре» («Агрызские вести») газетасында, "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре, экология, табигый ресурслар һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Л.Ф. Нургаянов